РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕКИБЯКОЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Ленина, д. 31
село Верхние Кибя-Кози,
422083
тел.(884360) факс: 56-5-42
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин урамы, 31енчейорт,
ЮгарыКибәхуҗа авылы,
422083
тел. (884360) факс: 56-5-42
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318107 ОГРН 1061675010836 ИНН/КПП 1619004443/161901001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№3

КАРАР
«01» февраля 2021г.

**Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.03.2017 елның 5 енче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының « Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 15 гыйнварындагы 11/13-09/111 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының 20.03.2017 елның 5 енче номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының «Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә:

А) 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча белән тулыландырырга:

«4) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитеты
житәкечесе

Ф.Р. Мәхмүтов